| | | |
|---|---|---|
| **ГЛАВА СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Урта Камышлы ав. | **КАРАР** |

**«10» октябрь 2025 ел** **№ 3**

**Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Абляскино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 27 октябрендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегенең Абляскино торак пунктында Пушкин урамында 1-43 йортларда, Лермонтов урамында 1-40 йортларда яшәүче гражданнар өчен Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Абляскино авылы адресы буенча урнашкан авыл кибетендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Урта Камышлы авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

3. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегенең Абляскино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Абляскино торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

- Устройство уличного освещения;

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуция челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Абляскино авылы мәгълүмат стендларында гражданнар

җыены этапларын уздыру датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы: В.П. Вафина